ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.08.2022 г. Заинск № 443

**«Зәй муниципаль районы мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын үзгәртү турында» 2018 елның 09 июлендәге 1142 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 566 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Зәй муниципаль районы мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын үзгәртү турында» 2018 елның 09 июлендәге 1142 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары (2018 елның 21 декабрендәге 1902, 2019 елның 26 декабрендәге 659, 2022 елның 27 гыйнварындагы 45 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре, муниципаль китапханәләр, музейлар, башка музей тибындагы учреждениеләр һәм мәдәни-ял учреждениеләре хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.17. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль китапханәләре, музейлар, башка музей тибындагы учреждениеләр һәм мәдәни - ял учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу өчен

мәдәният хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла.».

2. «Зәй муниципаль районы мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын үзгәртү турында» 2018 елның 09 июлендәге 1142 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары (2018 елның 21 декабрендәге 1902, 2019 елның 26 декабрендәге 659, 2022 елның 27 гыйнварындагы 45 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне керетергә:

2.1. 4.17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.17. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатларында, фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла.».

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р.Н.Камаловага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

А.Г. Бахусова
7 07 82
Юрист